# Уйный-уйный татар телен өйрәнәбез

Нурмиева Рәмзия Хатыбулловна
Казан шәһәре 360 нчы прогимназия

# ТАБЫШМАКЛАР

Йөртә ул озын колак,
Үзе гаҗәеп куркак.

Килә бер батыр атлап,
Аягы баса лап-лап.
Урманда йөри,
Умартадан бал көри

Энәсенең күзе юк,
Тегәр өчен җебе юк,
Яшерсә башын, аягын,
Ул нәни генә бер туп.

Йөз кат кием, барысы да төймәсез

Озын, яшел түтәлдә,
Сары, тозлы кисмәктә.

Кызыл кан кебек,
Татлы бал кебек.

Түгәрәк шардай, төсе кандай, тәме балдай

# Сүзләр белән бәйле биремнәр

# Артык сүзне тап

| | | | |
|---|---|---|---|
| икмәк | шикәр | итәк | сөт |
| язды | бара | пешерде | укыды |
| авыл | манара | чыршы | миләш |

# Буталган хәрефләр

| | |
|---|---|
| ә, з, ә, т, р. ә | тәрәзә |
| ә, ф, т. ә, д, р | дәфтәр |
| а, р, б, а | бара |
| й, ы, у, к | укый |
| я, ш, к, о | кояш |
| и, с, ө,й, л | сөйли |

# Килешләр

шәһәрдән

**Ю. к.**

әбинең

**И. к.**

**Т. к.**

урманга

**У-в. к.**

**Б. к.**

**Ч. к.**

сыйныфта

Алсуны

бүлмә

# СОРАУЛАР

сыйныфта КЕМ? урамга

КАЙДАН?

НӘРСӘ?

НИНДИ?

Казаннан

Кыш бабай КАЙДА?

КАЯ?

яшел

туп

шәһәрдә

абый

өстәл

# ХИКӘЯ ФИГЫЛЬНЕҢ ЗАМАН ФОРМАЛАРЫ

табачак

сөйләдең

әйтә

Хәзерге заман хикәя фигыль

укыды

килә

җырлаячак

Киләчәк заман хикәя фигыль

төзедек

кайтам

күрәчәкләр

Үткән заман хикәя фигыль

# Кроссворд сораулары

1. Кем кешеләрне дәвалый?
2. 5 тән соң нинди сан килә?
3. Әни әниеңнең  әнисе?
4. Салкын сүзенә нинди сорау куеп була?
5. Тукайның исеме?
6. Ул – белем чишмәсе?
7. Белем алу урыны?
8. Шагыйрь нәрсә иҗат итә?

2013 нче ел – табигатьне, әйләнә-тирәне саклау елы булып игълан ителде. Кроссвордны чишкәч, табигать сүзе килеп чыга.

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | Т | А | Б | И | Б | | | |
| | | | | | А | Л | Т | Ы | | | | |
| | | | | Ә | Б | И | | | | | | |
| | | | | Н | И | Н | Д | И | | | | |
| | | | | | Г | А | Б | Д | У | Л | Л | А |
| | | К | И | Т | А | П | | | | | | |
| | | М | Ә | К | Т | Ә | П | | | | | |
| Ш | И | Г | Ы | Р | Ь | | | | | | | |

# Җөмләдәге сүзләр тәртибен дөрес урнаштырырга

1. Кирәк, табигатьне, яратырга.
2. Татарстанның, суларга, бай, урманнарга, табигате.
3. Чыганагы, сәламәтлек, табигать.
4. Табигатьне, яратырга, кеше, тиеш.

1. Табигатьне яратырга кирәк.

2. Татарстанның табигате, суларга, урманнарга бай.

3. Табигать – сәламәтлек чыганагы.

4. Кеше табигатьне яратырга тиеш.